Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Кармәт авыл җирлеге составына керүче Иске Кармәт торак пунктында
үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2019 елның 24 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Иске Кармәт авыл җирлеге составына керүче Иске Кармәт торак пунктының халык җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге составына керүче Иске Кармәт авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә кулланырга:

I. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Иске Кармәт авылы урамнарын төзекләндерү (вак таш сатып алу һәм ташу, грунтлау һәм грейдлау, вак таш җәю);
- Иске Кармәт авылы кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту;

II. ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:

- мөселман һәм православие зиратларында ритуаль инвентарь саклау өчен хуҗалык корылмаларын урнаштыру.

3. Әлеге карарны Иске Кармәт авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат– телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырылган рәсми сайтында: http://aksubaevo.tatar.ru, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ игълан итәргә.

Иске Кармәт авыл җирлеге башлыгы А.В.Парфенов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН" СОВЕТ СТАРОКИРЕМЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ